СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 19 от 03.11.2020
На № ____________ от ____________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Уставына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында

2014 елның 19 декабрендә кабул ителгән 281 номерлы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131 номерлы Федераль законга һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131 номерлы Россия Федерациясе Федераль законының 44 статьясына яраштыру максатыннан, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын яңа редакциядә кабул итү турында” 2014 елның 19 декабрендәге 281 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча ачык тыңлауларны, Саба муниципаль районы Советының “Саба муниципаль районында ачык тыңлаулар турында нигезләмә проекты хакында”гы 2006 елның 21 ноябрендә кабул ителгән 94 номерлы карары белән расланган тәртиптә, 2020 елның 4 декабрендә сәгать 10да ТР, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т. б., Г. Закиров урамы, 52 йорт адресы буенча урнашкан муниципаль район Башкарма комитеты бинасының актлар залында үткәрергә.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне 2020 елның 3 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советына юлларга кирәк.

5. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проектын Интернет челтәрендә - Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru. рәсми порталында;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru. рәсми порталында;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибен Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru. рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының юридик бүлеге начальнигы А.И. Миникаевка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
2020 елның 3 ноябрендә
кабул ителгән 19 номерлы
карарына Кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль**
**Районы Уставына кертелә торган**
**үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты**

**1.** 7 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 15 пунктча өстәргә:

“15) полициянең участок вәкаләтле вәкиле вазыйфасын үтәгән хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны үтәү чорында торак урыны бирү.”.

**2.** 28 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:

“Район Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен аена ике эш көне күләмендә эш урынын (вазыйфасын) саклап калу гарантияләнә.”.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2020 елның 3 ноябрендә кабул ителгән 19 номерлы карары белән РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе.**

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына тәкъдимнәр, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советына, 422060, ТР, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т. б., Г. Закиров урамы, 52 йорт, 315 кабинет адресы буенча, язма рәвештә Саба муниципаль районы Советының оештыру бүлеге начальнигына кертелә.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында басылып чыккан көннән алып кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар 422060, ТР, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т. б., Г. Закиров урамы, 5 йорт, 315 кабинет адресы буенча шәхсән тапшырыла яки почта аша җибәрелә (Конвертта “Устав турында фикер алышу” дигән тамга булырга тиеш).